КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 19 сентябрь г.Казань № 713

«Мәктәпкәчә белем бирү буенча мәгариф программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Мәктәпкәчә белем бирү буенча мәгариф программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын расларга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы карамагындагы белем бирү учреждениеләрендә төп гомуми белем бирү программалары буенча мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 17 апрель, 260 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин